# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 3** 07.12.2019 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баланлы авыл җирлеге составына керүче Чия – Түбә торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Чия – Түбә торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Чия – Түбә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә. Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 350 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

— Чия – Түбә бистәсендә суүткәргечне ремонтлау

— Урам юлларын җәй көне карап тоту

— Территорияне төзекләндерү

— Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле үтүен тәэмин итү.

— Җирлекләрнең территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау

— Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү

— Урам-юл челтәре элементларына, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм махсус мәгълүмат стендларында, торак пунктлар территориясендә билгеләнгән тәртиптә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Баланлы авыл җирлеге башлыгы И.И.Исламова